**Бәйрәмнәребез**

# Балалар фестивален зурлап уздырдылар



**Талип хәзрәт Яруллин: «Рифкат, булдыра алмаган эшең юк. Инде изге Коръәнебезне үзләштерә башла»**



**Рифкат Хуҗин: «Җәмил абый, милли хәрәкәткә керткән хезмәтегез бихисап»**

Быелгы Балалар фестивале икеләтә бәйрәмгә әйләнде.

Беренчедән, тантана Самар шәһәр мохтариятенең 10 еллыгына туры килде, икенчедән, милли хәрәкәт тарихында беренче мәртәбә Кәрим Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры балаларга "Шүрәле" спектаклен күрсәтте.

Юбилей булгач, әлбәттә инде, тарих искә алына. Ә шәһәр мохтариятенең тарихы үкенерлек түгел.

Бәйрәмне алып баручы Наилә Сабирҗанова мохтарият әйдаманнарына тукталып, түбәндәге мәгълүматны бирде:



**Минәхмәт Хәлиуллов Федераль мохтарият исеменнән изге теләкләрен белдерде**

"Самар татар милли хәрәкәте үз яшәешендә балаларга зур игътибар күрсәтеп яшәде.

"Туган тел" җәмгыяте башлаган татар балалары бәйрәмен соңгы елларда Самар шәһәр татар милли-мәдәни мохтарияте үз җилкәсенә алды.

Мохтарият җитәкчесе - Туктаргали углы Рифкат Хуҗин.

Балаларга багышланган бәйрәмебез һәр елны үзенчәлекле уза. Сәбәбе бик гади - һәр елны төрле авыллардан төрле коллективлар килә. Ләкин дә һәр елны бер коллектив чыгыш ясамый калмас - ул Самардагы "Яктылык" мәктәбе укучылары.

"Яктылык" мәктәбе - ул безнең горурлыгыбыз! Менә бүген дә бәйрәмебезне "Яктылык" укучылары башлап җибәрделәр.

"Туган тел" җәмгыяте чирек гасыр буена бер дигән милли хәрәкәт лидерларын үстерде. Дәүләтебез Россиядә мохтариятләр турында яңа канун чыккач, татарлар Самар шәһәр татар милли-мәдәни мохтариятен оештырдылар.

Туганнар, бу аерылу түгел иде. Бу татар милли хәрәкәтендә үсеш баскычы булып кабул ителде. Самар шәһәр милли-мәдәни мохтарияте үз җилкәсенә ике бәйрәмне алды. Балалар фестивален һәм "Сөмбелә" бәйрәмен.

Татар милли хәрәкәте мәйданнарга, сәхнәләргә бәйрәмнәребезне генә кайтармады, ул әле горефгадәтләребезне саклау йөген дә үз җилкәсенә алды.

Шәһәр мохтариятенең рәисе итеп Әхмәдулла углы Җәмил абый Вәлиуллин сайланды.

Баһадир гәүдәле, олпат татарыбыз Вәлиуллин үз тирәсенә булдыклы, уңган, милләт йөрәкле, типсәләр - тимер өзәрлек яшь эшбатырларны туплап, җиң сызганып эшкә кереште. Әхмәдулла углы Җәмил Вәлиуллин тормыш мәшәкатьләренең сыртында барган зур предприятие җитәкчесе буларак, беренче булып намазга басты һәм хаҗи булды.

Җәмил абый Вәлиуллин шәһәр мохтариятен дә җитәкләде, "Туган тел"дә дә эшләде, Самар Җәмигъ мәсҗиден салуда да көч куйды.

Әгәр дә җәмгыять рәисен аның әгъзалары сайлап куйса, рәис үзенә директорны күңеленә хуш килгән һәм документация белән эшләргә маһир кешене үзе куя. Вәлиуллин директор итеп Садретдин углы Мансур Ямалетдиновны куйды. Һәм ялгышмады.

Мансур абый татар дөньясында беренче булып музыка мәктәбе укучылары башкаруында татар композиторларының әсәрләрен яңгыратты. Матди чыгымнарны тулысынча үз җилкәсенә алды.

Мансур абый Ямалетдинов - Самарда хәләл ит сатуны оештырган милләттәшебез.

Хөрмәтле тамашачыларыбыз!

Бүген бәйрәм.

Бүгенге бәйрәм - икеләтә бәйрәм.

Бүген Балалар фестивале дә, Самар шәһәр татар милли-мәдәни мохтариятенең 10 еллыгы да. Шуңа да без кыскача гына булса да, тарих башындагы шәхесләргә дә тукталдык".

Татар милли хәрәкәте уздырган һәр бәйрәмдә безнең хәзрәтләребез чыгыш ясый. Фестивальдә мөфтиебез Талип хәзрәт Яруллин нотык тотты. Ул үзенең чыгышын тулысынча балалар тәрбияләүгә багышлады.

"Самар шәһәр татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе Рифкат Хуҗинның балалар өчен зур тантана уздыруы мактауга лаек. Балалар эш белән мәшгуль булырга тиеш. Аларны урамнан сакларга кирәк. Биесеннәр, җырласыннар, спорт уеннарында катнашсыннар, тик вакытларын урамда гына уздырмасыннар. Әкренләп намазга да баса башласыннар", - дип түгәрәкләде чыгышын мөфтиебез Талип хәзрәт Яруллин.

Мөфтиебез мохтарият җитәкчесе Рифкат Хуҗинга Коръән бүләк итте.

Бу инде Рифкат әфәнде Хуҗинга өйгә эш биреп җибәрү буларак кабул ителде.

Чыннан да, Самар өлкә татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе Минәхмәт Хәлиуллов үзе дә, югары белемле улы да намазчы бит. Шулай булгач, Рифкат Хуҗин да милләт әйдаманы буларак, намазны җиңәр дигән өметтә калабыз.

Моңа бик көчле дәлилләр генә түгел, нигез дә бар. Мохтариятнең элеккеге җитәкчесе Җәмил Вәлиуллин да лидерларыбыз арасында беренче булып намазга да басты, хаҗи да булды.

Мөфтиебез чыгышыннан соң Тольятти шәһәренең 3нче музыка мәктәбендә белем алучы, "Якты йолдыз" фестиваленең Гран-при лауреаты Наил Исхаков Газинур Хаҗигалиевның "Дога кылыйк без" исемле җырын башкарып, дини тематиканы көчәйтте.

Наилә Сабирҗанова чыгышыннан тагын бер фикер:

"Самар шәһәр татар милли-мәдәни мохтариятенә - 10 ел!

Шул 10 ел эчендә җәмгыятьне ике кеше җитәкләде.

Беренчесе - Әхмәдулла углы Җәмил абый Вәлиуллин.

Җәмил абый Вәлиуллин шәһәр мохтариятенең нигез ташын да салды, диварларын да нык бастырды.



**Расыйх Латыпов: «Рифкатнең куйган хезмәтен күзәтеп барам. Яхшы эшли»**

Шәһәр мохтариятендә дистәгә якын бер дигән ирләр эшләде.

Җәмил абый аларның барчасын да бергә туплап, ныклы команда оештырды.

Буыннар алмашыну - табигый хәл.

Үзе ялга киткәндә мохтарият җитәкчесе итеп Туктаргали углы Рифкат Хуҗинны тәкъдим итте.

Беребез дә каршы килмәдек.

Чөнки Җәмил Вәлиуллин әйткән сүз - ул аткан ук!

Аңа һәрвакыт ышаныч зур иде.

Һәм ул ялгышмады.

Рифкат Хуҗин өлкән буын милләтпәрвәрләрнең йөзенә кызыллык китермичә, вазыйфаларын бик яхшы башкара. Яңа рәис яңа директорны үзе куя. Рифкат әфәнде Хуҗин урынбасары итеп зур укымышлы, инсафлы, битенә кызыллык китерми торган Илдар Тренгуловны алды.

Әхмәдулла углы Җәмил Вәлиуллинны тантанада лаеклы зурладылар һәм бүләкләр тапшырдылар.

Бүләкләр мулдин булды. Иң күп бүләкләр, әлбәттә, Самар шәһәр татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе Туктаргали углы Рифкат Хуҗинга бирелде.



**Наилә Сабирҗановага Самар мэры исеменнән Мактаунамә һәм Түшбилге тапшырылды**